# Катнаш кушма җөмлә

Берничә баш җөмлә янында бер яки күбрәк иярчен җөмлә килеп, компонентларны бәйләүдә тезүле бәйләнеш тә, ияртүле бәйләнеш тә катнашса, андый төзелмә **катнаш кушма җөмлә** дип атала.

1)Мин ул өйдән чыкканда, 2)бик күпләр, атларын туарып, утлауга җибәргәннәр, 3) хатын-кызлар учаклар тирәсендә мәш киләләр иде.

(- да ), [ ],[ ].

**Искәрмә:** катнаш кушма җөмләне тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә белән бутарга ярамый.

1)Карлар эре**гәч** 2) **һәм** сулар кит**кәч**, 3) бу иңкүлекне яшел үлән каплап ала.

( - гәч) һәм ( - кәч), [ ].

1)Карлар эре**гәч,** 2) сулар китә, 3) **һәм** бу иңкүлекне яшел үлән каплап ала.

( - гәч), [ ], һәм [ ].

# Катнаш кушма җөмлә компонентларын үзара бәйләүче чаралар

Бу төр җөмләләрдә тезүле бәйләнеш тә, ияртүле бәйләнеш тә була.

Тезүле бәйләнештә (ягъни баш җөмләләр арасында) булган бәйләүче чаралар: **санау яисә каршы кую интонациясе, тезүче теркәгечләр.**

Ияртүле бәйләнештә (баш җөмлә белән иярчен җөмләләр арасында) булган бәйләүче синтетик чаралар: **төрле кушымчалар, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, янәшә килү;** аналитик чаралар: **мөнәсәбәтле сүзләр**,  **ияртүче теркәгечләр**, **көттерү паузасы** керә.

# Катнаш кушма җөмлә компонентларын үзара бәйләүче чаралар

- *Юлга чык**саң**, ниятең изге булсын**,** яхшы юлдашлар да очрасын.*
- *Көн үткән **саен,** мин авыруның көчсезлегән күрәм, **һәм** терелүенә өмет тә сүнеп бара.*
- ***Кемнең** белеме бар, **шуның** кадере бар, аны хөрмәт тә итәләр.*
- *Җәй аена кер**сәк тә,** көннәр һаман салкын әле, **тик** күңел барыбер сөенә.*

# Катлаулы төзелмәләрнең төрләрен билгелә

1. Норадын дала кичкәндә,
   Айлар, көннәр үкәндә,
   Ялгыз улын сагынып,
   Идегәй аны җырлады.

2. Мин кергәндә, инде клуб эче шау-гөж килә, шатлык бөркелә иде.

3. Бу “Ана җыры” шундый йомшак булып ишетелде ки, күңелсезләнеп башларын игән кешеләрнең йөзләре яктырды, күзләре очкынланып китте.

# Катнаш кушма җөмләләр

1) Ташу безнең буага төртелү белән, агым әкренәйде, мәгәр суы күренеп арта башлады.

2) Аның тәне – монда, ә җаны яңгыр тамчылары биегән аланда иде.

3) Үткәндәге барлык авыр, кара көннәр онытылды, әйтерсең алар бөтенләй булмаган, бары тик хәзерге шатлыклы тормыш кына калды.

4) Галия дә яхшы белә, Хәлим дә төгәл хәтерли: ул елны күз җылы килгән иде.